ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

__________16.11.2023_____ №___174-од__________

г. Казань

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүнең өметсез булуын тану турындагы карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында” 2016 елның 6 маендагы 393 номерлыгы карары нигезендә

боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү тәртибен расларга.
2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З.Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының
_____2023____елның
______174-од____номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү
тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү тәртибе (алга таба - Тәртип) Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба - Дәүләт комитеты) идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүнең өметсез булуын тану процедурасын билгеләү максатларында эшләнде.

2. Дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр башкаручы физик затның үлеме яисә аны Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат дип игълан итү;

2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 127-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне башкаручы индивидуаль эшкуарның банкрот булуын тану - бурычлының мөлкәте җитмәү сәбәпле түләнмәгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч өлешендә;

3) индивидуаль эшкуар булмаган гражданны 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкрот дип тану - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң түләнмәгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч өлешендә;

4) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр башкаручы оешманың бетерелүе - Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә оешма мөлкәтенең җитмәве һәм (яисә) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләнә алмавы аркасында түләнми калган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар өлешендә;

5) штраф рәвешендә җәзага тартылуга хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында яисә ярлыкау турында актлар куллану яки бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр

буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалтуга нигез булган суд карары кабул ителү;

6) әгәр Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч барлыкка килү датасыннан биш елдан артык узса, суд приставы-башкаручы тарафыннан үтәтү эше тәмамлану турында һәм үтәтүчегә башкарма документны түләтүчегә “Үтәтү эшчәнлеге турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 229-ФЗ номерлы Федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча үтәтү документын кайтару хакында түбәндәге очракларда карар чыгарылу:

бурыч күләме банкротлык турындагы эш буенча эш кузгату өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында бурычлыга карата билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса;

суд тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне түләүчене банкрот дип тану турында гариза кире кайтарылса яисә банкротлык турындагы эш буенча үтәтү эше банкротлык турындагы эш буенча кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле туктатылса;

7) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан теркәү органы карары буенча юридик зат төшереп калдырылса, бу Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә белән раслана, һәм суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган үтәтү эшен 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документы түләтүчегә кире кайтарылуга бәйле рәвештә төгәлләү турында карар булса - Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда оешма мөлкәтенең җитәрлек булмавы һәм аны күрсәтелгән оешманы гамәлгә куючыларның (катнашучыларының) каплый алмавы сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләүләре буенча бурычы өлешендә; Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан юридик затны төшереп калдыру турында теркәү органы карары “Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында” 2001 елның 08 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пункт нигезендә элек түләтүгә өметсез дип танылган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) исәбендә торгызылырга тиеш.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәзаны билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар чыгарылган булса, түләтүгә өметсез дип танылa.

4. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүне өметсез дип тану турындагы карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

1) финанс исәпкә алуы һәм дәүләт сатып алулары бүлеге тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү буенча

бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында Дәүләт комитетының хисабыннан өземтәләр;

2) Дәүләт комитетының тиешле идарәдәге керемнәр чыганагы беркетелгән структур бүлекчәсе тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Дәүләт комитеты белешмәләре;

3) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүне өметсез дип тану очракларын раслый торган документлар, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне түләүче физик затның үлемен раслый торган яисә аны вафат дип игълан итү фактын раслый торган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

индивидуаль эшкуар булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне башкаручы гражданның мөлкәтен сату буенча конкурс эше төгәлләнү яисә сату төгәлләнү турында суд акты, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне башкаручы гражданның индивидуаль эшкуар буларак эшчәнлеге аны бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә туктатылу турында Бердәм дәүләт индивидуаль эшкуарлар реестрыннан белешмәләрне үз эченә алган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 2 пунктчада күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне башкаручы граждан мөлкәтен сату буенча конкурс эше төгәлләнү яисә сату төгәлләнү турында суд акты (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне башкаручы оешма юкка чыгарылуга бәйле рәвештә эшчәнлеген туктату турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан белешмәләр булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалту өчен нигез булган штраф рәвешендә җәзага тартылуга хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында яисә ярлыкау турында акт (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча үтәтү документы түләттерүчегә кире кайтарылуга бәйле рәвештә түләтү эше тәмамлану турында суд карары (күрсәтелгән очракта, әлеге Тәртипнең 2 пунктының 6 бүлегендә күрсәтелгән очракта);

бурычлыны бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип тану яки банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек чаралар булмауга бәйле рәвештә банкротлык турында эш буенча башкаруны туктату турында гаризаны кире кайтару хакында суд акты (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 6 пунктчаның өченче абзацында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне башкаручы юридик затны Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан теркәүче орган карары буенча төшереп калдыру турында күрсәтелгән реестрдан белешмәләрне үз эченә алган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 7 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар (әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта).

5. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану эшен оештыру максатларында Дәүләт комитеты боерыгы белән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны юкка чыгару буенча Дәүләт комитетының даими эшче комиссиясе (алга таба - Комиссия) җиде кеше составында төзелә.

Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре, Комиссия әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукка ия.

Комиссияне Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче рәис җитәкли. Комиссия рәисе булмаганда, аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссиянең персональ составы Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

6. Дәүләт комитетының тиешле идарәдәге чыганак беркетелгән структур бүлекчәсе, Дәүләт комитетына әлеге Тәртипнең 2 яисә 3 пунктларында каралган очрак барлыкка килү турында мәгълүмат кергәндә, әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч түләтүнең өметсез булуын тану нигезләрен раслаучы документлар пакетын төзи, һәм ул ай саен Комиссиягә карауга җибәрелә.

7. Комиссия утырышлары ихтыяҗ булуга карап уздырыла, ләкин елына бер тапкырдан да сирәк түгел.

Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, хокуклы була.

Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия әгъзалары имза сала.

8. Комиссия шушы Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар кергән көннән алып ун эш көне эчендә документларны карый һәм ачык тавыш бирү юлы белән Комиссия утырышында катнашучы әгъзалары саныннан тавышларның гади күпчелеге белән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча түләтүләрнең өметсез булуын тану турында яисә аны танудан баш тарту турында карар кабул итә. Тавышлар тигез булганда, Комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

9. Комиссия карары Комиссия утырышы көненнән алып ун эш көне эчендә түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

а) оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

б) салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, код, салым түләүче оешманы исәпкә кую сәбәпләре (салым түләүче физик затның идентификация номеры (булган очракта));

в) бурыч барлыкка килгән Татарстан Республикасы бюджетына түләү турында белешмәләр;

г) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч , исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджетлары керемнәре классификациясе коды;

д) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч суммасы;

е) Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

ж) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул ителү датасы;

з) Комиссия әгъзаларының имзалары.

Акт ике нөсхәдә төзелә һәм Комиссия рәисе һәм Комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

10. Акт ун эш көне дәвамында Дәүләт комитеты Рәисе тарафыннан раслана.